РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.01.2021 Буа шәһәре № 18/ИК-п

Социаль ярдәм чараларын билгеләү турындагы
Буа район башкарма комитеты карарына үзгәрешләр
кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Буа район башкарма комитетының «Социаль ярдәм чараларын билгеләү турында» 2006 елның 16 августындагы 306 номерлы карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 3 пункт:

түбәндәге редакциядә абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә бирү ярдәм итү чарасын алуның мәҗбүри шарты булып тора.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үз өстемә йөклим.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы А.Р. Вәлиуллов